КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　БОЕРЫК

«12» октябрь 2023 ел. № 179-п

Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы
дәүләт телләрен популярлаштыру буенча
республика конкурсын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «2023 - 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында боерам:

1. Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча республика конкурсын үткәрү турында кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ф.Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　А.С.Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2023 елның _12 октябрь _179-п___ номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча республика конкурсы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «2023-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча еллык республика конкурсын оештыру һәм уздыру тәртибен, шартларын билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Оештыручы).

1.3. Конкурс 2023 елның 15 – 30 ноябрендә уздырыла.

Конкурсны уздыру турында мәгълүмат Оештыручының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырыла: http://tatmedia.tatarstan.ru «Яңалыклар», «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә (алга таба – Оештыручының рәсми сайты). Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүматта конкурс уздыру шартлары, номинацияләр, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары һәм тәртибе, гаризаларны кабул итә башлау һәм тәгәлләү вакыты, аларны тапшыру тәртибе, бүләкләү күләме һәм рәвеше, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

## 2. Конкурсның максатлары

2.1. Конкурсның төп максаты – Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклауга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән иң яхшы блогларны ачыклау.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклауга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән заманча технологияләр ярдәмендә контент булдыручы һәм алга этәрүче блогерларны хуплау һәм бүләкләү;
- Татарстан Республикасында блогосфера үсешен стимуллаштыру.

## 3. Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

блог – вакыйгаларның интернет-журналы, социаль челтәрләрдә аккаунт яисә төркем, мессенджерларда яисә видеохостингларда канал, аларның төп эчтәлеге Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклауга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән тексттан, сурәттән яисә мультимедиадан гыйбарәт даими өстәлә торган язмалар булырга тиеш;

шәхси блог - блог бер зат белән алып барыла, блогта авторлык һәм уникаль контент бар;

блогер – Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклауга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән үз сайтын, социаль челтәрләрдә аккаунтын яки мессенджерларда һәм видеохостингларда канал алып бара торган, язылучылар яисә укучылар санына бәйсез рәвештә, интернет-кулланучы;

блогосфера – барлык блоглар җыелмасы;

контент – блог эчтәлеге;

пост – блогтагы аерым бер хәбәр;

конкурста катнашырга гариза бирүче – әлеге Нигезләмәнең 5 бүлеге нигезендә гариза биргән блогер (алга таба – гариза бирүче);

катнашучылар – конкурста катнашу рөхсәт ителгән гариза бирүчеләр (алга таба – катнашучылар);

конкурс комиссиясе – блогерлар материалларын бәяләүче затлар төркеме;

Конкурста җиңүче – призлы урынны алган катнашучы.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста Россия Федерациясе гражданнары булган, 14 яшькә җиткән, шәхси блоглар алып баручы физик затлар катнаша. «Иң яхшы яшь блогер» номинациясендә 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге физик затлар катнаша.

4.2. Конкурста катнашу өчен гариза бирүчеләр Оештыручыга гаризаны әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә каралган тәртиптә тапшыра.

4.3. Гариза бирүче конкурсның бер номинациясенә бер генә гариза бирә ала.

4.4. Гариза бирүче, һәр номинациягә гаризаны әлеге Нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә аерым формалаштырган очракта, берничә номинация буенча гариза бирә ала. Бер үк конкурс эше Конкурсның төрле номинацияләренә бирелә алмый;

4.5. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылыкны, блоглар тәкъдим иткән гариза бирүчеләр (катнашучылар) законнар нигезендә алып баралар.

## 5. Конкурсны уздыру шартлары һәм тәртибе

5.1. Конкурска Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклап калуга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән блоглар тәкъдим ителә.

5.2. Гариза түбәндәге документларны үз эченә ала:

блогка актив сылтама күрсәтеп, катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә анкета;

паспортның яисә Россия Федерациясе гражданының шәхесен таныклый торган башка документның күчермәсе (2 нче һәм 3 нче битләр);

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (тәкъдим ителә торган форма әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада бирелә);

шәхси мәгълүмат субъекты тарату өчен рөхсәт иткән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (тәкъдим ителә торган форма әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада бирелә);

5.3. Гариза электрон саклагычларда почта аша 420066, Татарстан Республикасы, Декабристлар урамы, 2 нче йорт, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге, 608 кабинет адресына яки Конкурс уздыру турындагы игъланда күрсәтелгән электрон почта адресына юллана. Белешмәләр өчен телефон Конкурсны уздыру турындагы игъланда күрсәтелә.

5.4. Оештыручы гариза бирүчене түбәндәге очракларда Конкурста катнашучылар исемлегенә кертми:

гариза әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

конкурста катнашуга гариза бирү срогы бозылу;

блог әлеге Нигезләмәнең 5.7 пунктында билгеләнгән Конкурс предметына туры килмәү;

интернет - ресурсларга (социаль челтәрләргә) урнаштырылган блог, аларга керү Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән;

блогта «Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында» 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә экстремистик дип танылган материаллар бар;

мөрәҗәгать итүче «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия;

«Иң яхшы яшь блогер» номинациясенә гариза бирүченең яше 14 – 18 яшь критериена туры килмәү.

5.5. Гариза бирүчегә конкурста катнаштырудан баш тарту турында Оештыручы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) тарафыннан имзаланган һәм анкетада күрсәтелгән адрес буенча Оештыручы тарафыннан гариза алынган көннән алып өч эш көне эчендә юлланган заказлы хат белән хәбәр ителә.

5.6. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һәм башкалар) гариза бирүчеләр һәм катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.7. Конкурс предметы – Татарстан Республикасы дәүләт телләрен саклап калуга һәм популярлаштыруга юнәлдерелгән, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 8.3 пунктында күрсәтелгән тиешле номинацияләргә туры килә торган блоглар контенты.

5.8. Блогосферада материаллар урнаштыру чоры Конкурсны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелә.

5.9. Блогка керү конкурс уздыру чорында ачык булырга тиеш.

5.10. Конкурста катнашучылар тарафыннан материаллар тапшырылганда авторлык хокукы һәм интеллектуаль милек турындагы законнар таләпләре үтәлергә тиеш.

5.11. Реклама хокукында урнаштырылган материаллар конкурста катнашуга кертелми.

## 6. Конкурсның бәяләү критерийлары

Блогларны бәяләү критерийлары:

эчтәлекнең актуаль булуы (сыйфат, оригинальлек) (0-5 балл);

статистика (аудитория (0-5 балл);

бизәлеш (дизайн, стилистика) (0-5 балл).

## 7. Конкурс комиссиясен төзү һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1. Конкурс комиссиясе составы Оештыручы боерыгы белән 5 кеше составында раслана һәм комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

7.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез нигездә гамәлгә ашыра.

7.3. Конкурс комиссиясе эше аның утырышларында башкарыла. Утырыш, әгәр анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

7.4. Конкурс комиссиясе эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары конкурс комиссиясе рәисе урынбасарына йөкләнә.

7.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары әлеге Нигезләмәнең 6 бүлегендә билгеләнгән һәр критерий буенча тәкъдим ителгән блогларны бәялиләр. Һәр критерий буенча Комиссия әгъзасы тарафыннан куелган балл суммасы блог Комиссиясе әгъзасы бәяләмәсе булып тора. Комиссия әгъзаларын бәяләү суммасы блогның йомгаклау бәяләмәсен тәшкил итә. Бәяләү нәтиҗәләре буенча блоглар рейтингы төзелә. Блоглар рейтингы конкурс комиссиясенең йомгаклау беркетмәсендә теркәлә. Рейтинг нигезендә конкурс комиссиясе конкурста җиңүчеләр исемлеген төзи.

7.6. Блокларның йомгаклау рейтингында 1, 2, 3 урыннарны алган Конкурста катнашучылар конкурс җиңүчеләре дип танıла. «Иң яхшы яшь блогер» номинациясендә конкурста җиңүчеләр дип танıла, аларның блоглары рейтингта 1, 2, 3, 4 урыннар алса.

7.7. Бер үк санда баллар җыйган конкурста ике һәм аннан күбрәк катнашучы булганда, җиңүче тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан гади күпчелек тавыш белән билгеләнә. Җыелган баллар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче тавыш хәлиткеч булып тора.

7.8. Бер номинация буенча бер гариза да бирелмәгән очракта, бирелгән гаризаларның берсе дә конкурс критерийларына туры килмәсә, номинациядә җиңүче билгеләнмәсә бу номинация буенча конкурс узмаган дип танıла, бу номинация буенча премияләргә бүлеп бирелгән акчалар Оештыручы тарафыннан тигез өлешләрдә башка номинацияләргә бүленә.

7.9. Блокларны бәяләү һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре йомгаклау беркетмәсендә чагыла, аңа утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзалары имза сала һәм конкурс комиссиясе рәисе раслый (конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, йомгаклау беркетмәсе конкурс комиссиясе рәисе урынбасары раслый).

7.10. Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча җаваплы секретарь тарафыннан беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары, рәис урынбасары имза сала һәм ул конкурс комиссиясе утырышы узган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

7.11. Конкурс йомгаклары беркетмәгә имза салынган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә Оештыручының рәсми сайтына урнаштырыла.

## 8. Финанслау

8.1. Конкурсны оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендәге 821 номерлы карары белән расланган «2023–2030 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

8.2. Гомуми акчалата приз фонды 2023 елда 565 мең сум тәшкил итә.

8.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| № | Номинацияләр | Урнашкан урыны | Сумма (мең сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1. | «Социаль челтәрләрдә иң яхшы блог» | 1 урын | 50 000 |
| | | 2 урын | 40 000 |
| | | 3 урын | 30 000 |
| 2. | «Видеохостингларда иң яхшы блог» | 1 урын | 50 000 |
| | | 2 урын | 40 000 |
| | | 3 урын | 30 000 |
| 3. | «Мессенджерларда иң яхшы блог» | 1 урын | 50 000 |
| | | 2 урын | 40 000 |
| | | 3 урын | 30 000 |
| 4. | «Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елы темасы буенча иң яхшы блог» | 1 урын | 50 000 |
| | | 2 урын | 40 000 |
| | | 3 урын | 30 000 |
| 5. | «Иң яхшы яшь блогер» (яше 14 яшьтән 18 яшькә кадәр) | 1 урын | 30 000 |
| | | 2 урын | 25 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 3 урын | 15 000 |
| | | 4 урын | 10 000 |

8.4. Физик затларга акчалата премияләр Оештыручыга җибәрелгән хатта күрсәтелгән банк счетларына җиңүчеләр игълан ителгәннән соң акча күчерү юлы белән конкурс йомгакларын ясау турындагы беркетмәгә имза салынган көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган 20 көн эчендә түләнә.

8.5. Җиңүчеләрне бүләкләү датасы һәм урыны турында өстәмә рәвештә Оештыручының рәсми сайтында игълан ителә.

8.6. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә.

## 9. Махсус шартлар

Оештыручы түбәндәгеләргә хокуклы:

әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, шулай ук бәхәсле хәлләр барлыкка килгән очраклардан тыш, катнашучылар белән язма хәбәрләр алышмаска яисә башка элемтәләргә кермәскә;

Конкурсны гамәлдән чыгарырга яисә аның шартларын, Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, конкурс эшләрен тәкъдим итү өчен билгеләнгән срокның беренче яртысы дәвамында үзгәртергә, катнашучыларга Оештыручының рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2023 елның ____ ________
______ номерлы
боерыгы белән расланган
Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча республика конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

| **Конкурста катнашуга анкета-гариза** | |
|---|---|
| Фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) *(әгәр материаллар псевдоним астында басылса, аны җәяләр эчендә күрсәтергә кирәк)* | |
| Контактлар (телефон, e-mail) | |
| Блог исеме | |
| Блогка актив сылтама | |
| Укучылар санын күрсәтү (скрин) | |
| Конкурс номинациясе | |
| Контентның эчтәлеге турында мәгълүмат (кем өчен, колачлау – лайклар саны, шәрехләүләр, гариза бирелгән датага караулар) | |
| Катнашучының шәһәре (торак пункты) | |
| Мөрәҗәгать итүченең банк реквизитлары (банк исеме, гариза бирүченең шәхси счеты, банкның исәп-хисап счеты, банкның корреспондент счеты, БИК банк, ИНН банк, КПП банк) | |

Автор __________ ______________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

2023 елның ____ ____________

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2023 елның ____ ________
 ______ номерлы
боерыгы белән расланган
Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча республика конкурсы турында нигезләмәгә
2 нче кушымта
(Тәкъдим ителә торган форма)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,__________________________________________________________________,
яшәү адресым_______________________________________________

__________________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________

_____________________________________________________________________________

_________________________________, “Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча республика конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

| | |
|---|---|
| Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ | (фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон |

| | |
|---|---|
| белешмәләрнең исемлеге: | почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр) |

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

_______________________________________________________________/______________

(персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы)

_______________

(Дата)

---

*Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2023 елның________ ______ номерлы боерыгы белән расланган Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча республика конкурсы турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

(Тәкъдим ителә торган форма)

**Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________________,

(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта) рус телендә)

________________________________________________________________________,

(почта адресы)

________________________________________________________________________,

(электрон почта адресы)

________________________________________________________________________,

(телефон номеры)

“Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру буенча республика конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Ризалык |
| --- | --- | --- |

| | | Әйе | ЮК |
|---|---|---|---|
| Гомуми персональ белешмәләр | | | |
| | Фамилия | | |
| | Исем | | |
| | Атасы исеме (булган очракта) | | |
| | Туган ел, ай, дата һәм урын | | |
| | Адрес | | |
| | Белем | | |
| | Һөнәр | | |

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1. [Персональ белешмәләрнең категориясе] | | |
| | [Персональ белешмәләрнең исемлеге] | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла.

Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота.

Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык _____________________________ срокта гамәлдә була.

**(ризалыкның гамәлдә булу срогы)**

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.

Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

______________(персональ белешмәләр субъекты имзасы)

______________ (число, ай, ел)